**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**

423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”
тел.+7(84396) 2-64 -66
тел./факс +7(84396) 2-64-66
423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ, УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»

№ 123 19 сентябрь 2019 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘРКӘТӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## Референдум үткәрү инициативасы турында

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Бәркәтә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2009 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 44 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Киләсе мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүгә башлангыч бирү: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 һәм 2 төркем инвалид, 80 һәм аннан өлкәнрәк, күп балалы аналардан тыш Бәркәтә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- "Чишмә" елгасы аша җәяүлеләр кичү юлын төзү.

Проект һәм тикшеренү эшләре(инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы), объект төзелеше.

- Бәркәтә торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);
- Бәркәтә торак пунктында зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймалар урнаштыру (ремонтлау), урна урнаштыру, агачларны кисү, корыган-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар (хезмәтләр күрсәтү) сатып алу;
- җәй һәм кыш айларында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдерлауга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, хезмәт күрсәтүгә, запас частьләр сатып алуга), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Бәркәтә торак пунктында сусүткәргеч челтәрләренең проект һәм тикшеренү эшләре(инженерлык эзләнүләре, проект эшләре, проект экспертизасы);
- Бәркәтә авылында йорт номерлары һәм урам исемнәре язылган табличкалар (ике телдә)

ӘЙЕ ЮК»

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

.

Башлык, Бәркәтә
авыл җирлеге Советы рәисе Г.Х.Гайнанова